РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

СОВЕТ
Нижнекамского муниципального района

423570, г.Нижнекамск, пр.Строителей,12
факс (8555) 41-70-00, тел.42-41-41

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

Түбән Кама муниципаль районы
СОВЕТЫ

423570, Түбән Кама шәһәре, Төзүчеләр пр., 12
факс (8555) 41-70-00, тел.42-41-41

РЕШЕНИЕ КАРАР

№ 17 2020 елның 16 октябре

Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы «Афанас авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 33 статьясы, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы Уставы нигезендә, Түбән Кама муниципаль районы Советы

КАРАР БИРӘ:

1. 2013 елның 5 мартындагы 31-117 номерлы Түбән Кама муниципаль районы Афанас авыл җирлеге Советы раслаган «Афанас авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренең график өлешенә үзгәрешләр кертергә:

1.1. Покровская ур. һәм Кызыл ур. буенча Олы Афанас авылындагы җир кишәрлекләре территориаль зонасын СУ авыл хуҗалыгы җирләреннән Ж-1 шәхси торак йортлар төзелеше зонасына кушымта нигезендә үзгәртергә;

1.2. 16:30:010801:225 кадастр номерлы һәм 16:30:010801:325 кадастр номерлы җир кишәрлекләре территориаль зонасын СУ авыл хуҗалыгы җирләреннән ИТ-2 транспорт инфраструктурасы зонасына үзгәртергә;

1.3. 16:30:010801:3 кадастр номерлы, 16:30:010801:410 кадастр номерлы, 16:30:010801:411 кадастр номерлы җир кишәрлекләре территориаль зонасын, 16:30:010801:341 кадастр номерлы җир кишәрлеге өлешен СУ авыл хуҗалыгы җирләреннән ПК-1 куркынычлыкның IV-V класслы җитештерү-коммуналь объектлар зонасына үзгәртергә.

2. Афанас авыл җирлеге территориясеннән «Бигеш» аэропортының аэропорт яны территориясе» территорияне файдалануның аерым шартлары булган зонаны алырга.

3. Әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларының матбугат басмаларында, Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районы һәм Афанас авыл җирлеге рәсми сайтларында бастырып чыгарырга.

4. Интернет челтәренә кертелгән үзгәрешләр белән «Афанас авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен урнаштырырга.


5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны төзелеш, җир төзелеше, торак-коммуналь хуҗалык һәм транспорт буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Түбән Кама муниципаль
районы Башлыгы А.Р.Метшин

ПРЕДСТАВИТЕЛЬНЫЙ ОРГАН
ВӘКИЛЛЕКЛЕ ОРГАН

Түбән Кама муниципаль
районы Советының
2020 елның 16 октябрендәге
17 номерлы карарына
кушымта

**до внесения изменений**




**после внесения изменений**




Түбән Кама муниципаль
районы Башлыгы урынбасары Т.Р.Гәрәев